КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 26 сентябрь г.Казань № 763

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 14 август, 569 нчы карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2017 ел, 14 август, 569 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 декабрь, 1064 нче; 2020 ел, 16 октябрь, 935 нче; 2022 ел, 4 апрель, 314 нче; 2022 ел, 19 август, 865 нче; 2022 ел, 15 сентябрь, 1007 нче; 2024 ел, 10 май, 315 нче; 2024 ел, 12 сентябрь, 780 нче; 2025 ел, 17 апрель, 238 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Граждан-

нар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына, әлеге Методиканың 2 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объект-ларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнә-сәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль район-нары һәм шәһәр округлары бюд-жетлары чыгымнары күләмен билге-ләү методикасына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 26 сентябрь, 763 нче
карары редакциясендә)

Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү өчен кулланыла торган
вазыйфаи окладлар күләмнәре

| Т/с | Хезмәткәрләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1. | Учреждение җитәкчесе | 33 345 |
| 2. | Оператив кизү торучы | 25 650 |

________________________